**Заһидә НӘБИУЛЛИНА,**
*журналист*

# ЗУР ДӘРЬЯЛАР ЧИШМӘЛӘРДӘН БАШЛАНА

Мин 1963 елның июнендә «Коммунизм байрагы» газетасында тәрҗемәче булып эшли башладым. Шунысы куандырды безне, газета мәйданының 40 процентына үзебезнең, ягъни татарча язучы хәбәрчеләрнең шигырьләрен, хикәяләрен урнаштыру мөмкинлеге бирелде. Ә язмалар, бигрәк шигырьләр күп килә иде.

Татарча басманың мөхәррире, сугыш юлларын узган журналист Хәнәфи ага Маннапов яшь талантларга искиткеч игътибарлы, кече күңелле, ярдәмчел кеше булды. Ә өлкән тәржемәче Зәйнәп апа Җиһаншина әдәбиятка мөкиббән җан иде. Киңәшләштеләр дә, редакция каршында яшь каләм тибрәтүчеләр өчен әдәби берләшмә оештырып җибәрергә булдылар. Газетабызда инде Хәниф Хөснуллин, Рафис Хисамиев, Фәннур Сафин, Разил Вәлиев, Мөдәррис Әгъләмов, Сәлимә Шәриповаларның шигырьләре еш басыла иде...

Берләшмәнең оештыру мөслихәтен Татарстан Язучылар берлеге хуплады һәм утырышларга киңәшче итеп шагыйрьләр җибәрергә вәгъдә иттеләр.

Беренче утырыш бик истә калган. 1963 елның октябре булырмы, Яңа ел алдыннан сыман да тоела, газетага әдәби берләшмә оешачагы һәм аның көне, сәгате турында игълан бирдек. Билгеләнгән вакытны ничектер үзебез дә бәйрәмдәй көтеп алдык. Эш көне тәмамланырга бер-ике сәгать калгач, бүлмәгә базык гәүдәле, киң җилкәле, бүрегеннән җирән чәче чыгып торган, бераз гына сипкелле егет килеп керде. Ачык йөзле, мөгамәләсе бик әдәпле, күзләреннән нур бөркелеп тора. Эчкерсез, хисле кешеләрдә генә була торган җылы караш.

– Газетаны шигырьләр белән «чүпләүче» Хәниф Хөснуллин булам мин. Биклән мәктәбе укытучысы, – дип үзе белән таныштырды, барыбыз белән дә кул биреп күреште. Һәм алар Хәнәфи ага белән шигърият турында сөйләшеп киттеләр. Күренеп тора, егетнең белем «капчыгы» шактый саллы, фикерләре тирән, үзсүзлерәк кеше булуын ди сиздерде.

Оештыру утырышына, вәгъдә ителгәнчә, танылган шагыйрь Зәки Нури килде. Башта яшь каләм ияләре белән аерым-аерым танышты, шигырьләрен укыды. Араларында IX сыйныф укучылары Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиев, Рәүф Гыйззәтуллин, Анатолий Цыганов, алардан аз гына өлкәнрәк Сәлимә Шәрипова, Мөнир Талипов, Мөслах Таҗиев һ.б. бар иде.

Зәки Нури (Язучылар оешмасында фикерләшкән булыр) институтта укыганда ук «Татарстан яшьләре» газетасында шигырьләре басылган Хәниф Хөснуллинны берләшмә җитәкчесе итеп сайларга тәкъдим кертте. Хәниф бу җәмәгать эшенә шул кадәре җитди карады, атна саен редакциягә килә, шигырьләрне анализлый, әйбәтләрен газетага тәкъдим итә, яшьләр белән очраша, киңәшләр бирә. Укучы балаларның һәр уңышлы шигыре, дөресрәге, берничә юлы өчен дә сабыйдай куана: карагыз әле, тыңлап кына карагыз, ничек әйткән бит, нинди деталь тапкан бит, дияр иде.

Аның әнә шундый җанлы эше нәтиҗәсендә берләшмә үзенә бик күп талантларны җәлеп итте. Һәр утырышка (ә ул ай саен узды), язучылар килә. Ерак авыллардан килүчеләрне, ә ул чагында Түбән Кама, Зәй яклары барысы да Чаллы районына керә иде, кунакханәгә урнаштырабыз, ведомость төзеп, юлларына түлибез, һәр утырышның беркетмәсе алып барыла: бу эшләр мин фәкыйрегезгә йөкләнгән иде һәм әлбәттә, мин аларны зур җаваплылык белән башкардым.

Берләшмә утырышларына Мәхмүт Хөсәен, Рәшит Гәрәй, Клара Булатова, Саҗидә Сөләйманова, Сибгат Хәким еш килде. Ә 1965 (хәтерем ялгышмаса) яшь каләм ияләре белән очрашуга язучылар бригадасы: Хәсән Туфан, Салих Баттал, Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Габдрахман Әпсәләмов, Шәйхи Маннур килде. Берләшмәдә очрашканнан соң алар мәктәпләрдә булдылар, авылларда, шәһәр мәдәният йортында очрашулар үткәрделәр.

Шәһәр һәм авыл бер булып атна буе әдәби бәйрәм мохитында яшәде. Андый очрашуларны зарыгып көтеп алалар, шыгрым тулы залда, бик җанлы үтә иде алар.

Әдәби берләшмәгә тора-бара композиторлар Зөфәр Сәгыйтов, Хәмит Булатов, халык театры режиссеры Мансур Кашапов йөри башлагач, без аның исемен әдәбият-иҗат берләшмәсе дип үзгәрттек. Композиторлар шагыйрьләрнең сүзләренә көйләр язды, Зәйнәп Җиһаншинаның «Төнге шәүләләр» драмасы китап булып басылып чыкты. Мансур ага рус, башка милләт язучыларының пьесаларын тәрҗемә итеп, сәхнәгә куйды. Яшь шагыйрьләребезнең шигырьләр тупланган «Беренче карлыгачлар» китабы дөнья күрде.

Бу мәкаләмне язганчы ук мәрхүмнәр Хәнәфи ага, Зәйнәп апаны сагынып, рәхмәт хисләре белән искә алдым. Яшь талантларны күрә, аларны ачу, үстерү юлларын таба белгәннәр. Берләшмәбездә «тәпи киткән» Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиев, Фәннур Сафин танылган шагыйрьләр булдылар, Рафис Хисамиев гомере буе төзелештә эшләде, үзенең шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарды. Мансур аганың да китабы дөнья күрде, ә Зөфәр Сәгыйтовның җырлары әле бүген дә Татарстан һәм Чаллы радиоларыннан янгырый. КАМАЗ төзелеше шәһәрнең әдәби дөньясына да яңа сулыш, яңа талантлар алып килде. Шәһәрдә Татарстан Язучылары берлеге бүлеге ачылды. Һәм газета каршында гөрләп эшләп килгән әдәбият-иҗат берләшмәсе шул бүлек канаты астына күчте. Кызганычка каршы, утырышларның һәрберсен, язучыларның киңәшләрен, теге яки бу каләм тибрәтүче биргән бәяләмәләрен язып барган беркетмә югалды. Әмма берләшмә озын гомерле булды. «Ләйсән» дип аталган иҗат көчләрен бергә туплаган бу рухи чишмә бүген дә агымын дәвам итә.

*2008 ел. Яр Чаллы.*